СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.13, д. Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яшьләр ур, 13 йорт, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**Урта Курса авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**26.01.2016 ел** **№ 2**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2016 елның 22 гыйнварындагы Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитеты карары нигезендә Урта Курса авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2016 елның 13 мартына Урта Курса авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

«2016 елда Урта Курса авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 800 сум күләмендә үзара салым кертү (түләү күләме 200 сум тәшкил иткән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, балачактан инвалидлар тыш, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен) 1әм акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү | - торак пунктларга янгын гидрантлары сатып алу;:<br>Түбән Курса авылы<br>Алан авылы<br>Корайван авылы | <br><br>6 000<br>6 000<br>6 000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | юлларны ремонтлау (вак таш, торбалар сатып алу).<br>Югары Курса авылы<br>Урта Курса авылы<br>Түбән Курса авылы<br>Алан авылы<br>Сарай-Чокырча авылы | <br><br>100 000<br>60 000<br>110 000<br>60 000<br>46 000 |
| 3 | Күмү урыннарын карап тоту | - зират коймаларын урнаштыру һәм карап тоту:<br>Урта Курса авылы<br>Корайван авылы | <br><br>25 000<br>15 000 |
| 4 | Төзекләндерү эшләрен оештыру | - Урта Курса авылында чишмә ремонтлау,.<br>- Алан, Корайван, Урта Курса, Югары Курса авылларында яшел үсентеләрне санитар кисү;<br>- Урта Курса авыл җирлеге составына керүче барлык торак пунктларда урам яктырткычларын алыштыру һәм урнаштыру | 3 000<br><br>10 000<br><br><br>10 000 |
| 5 | Халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | - кое ремонты.:<br>Алан авылы<br>Югары Курса авылы; | <br>17 000<br>30 000 |
| | | Барлыгы: | 510 000 |

әйе юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга: Урта Курса авылы, Яшьләр ур., 13, Урта Курса авылы, Сәйдәш ур., 8.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина

СОВЕТ СРЕДНЕКОРСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ